ПЕРВОЕ ИСПЫТАНИЕ



С возрастом, когда появляется свободное время для раздумий или возможность высказаться, начинаешь как бы заново осмысливать жизнь свою или других людей и прошлые события. Для меня такой темой является жизнь моего отца — профессора Исмагила Гадиевича, яркого представителя национальной интеллигенции. Как-то Зиля Гаяновна Магиярова*, собирающая сведения об уроженцах Чекмагушевского района Башкортостана, попросила меня предоставить биографические данные о моем отце, профессоре И. Г. Сулейманове[1]. Готовясь к встрече с ней, я вспомнил, что в семейном архиве остались многочисленные документы и воспоминания моего отца. Воспоминания, в стихах и в прозе, он писал последние год-два своей жизни, хотел опубликовать их, но не успел. Тогда, более тридцати лет назад, у меня не было возможности заняться разбором его литературного наследия, оригиналы которого написаны на основе арабской графики, а потом переведены на кириллицу. Теперь же я прочитал все записи и, в свою очередь, перевел их еще и на русский язык.

Жизнь Исмагила Сулейманова (1904-1973) складывалась нелегко. В семье росло шесть детей. В самом начале 1918 г. умер отец. Гражданская война не давала возможности нормально вести хозяйство. «Вилочный» мятеж в начале 1920 г., докатившийся до деревни Старое Баширово, чуть не закончился трагически для самого старшего брата — учителя, да и для всей семьи. Беды голодного 1921 года начались с того, что пала единственная лошадь. Но самым трагическим событием стала смерть от голода матери[2].

В 14-15 лет Исмагил стал основным работником в семье[3] и оставался им до тех пор, пока не подросли младшие дети, пока он сам не закончил школу-семилетку. К этому времени он уже обрел свою цель — стать специалистом сельского хозяйства. Исма-

* З. Г. Магиярова — кандидат педагогических наук, доцент КГТУ (КАИ).

гил поступил на учебу в Миловский совхозтехникум, который закончил с отличием в 1930 г. Успев недолго поработать агрономом, он пришел по призыву в Красную Армию, был направлен на юг Туркмении на борьбу с басмачами. После демобилизации он снова работал. Но мечта стать высококвалифицированным специалистом-биологом привела его в Казань в университет.

С отличием закончив Казанский университет, Исмагил Сулейманов через некоторое время начал работать на университетской кафедре физиологии растений, служению которой он посвятил всю оставшуюся жизнь, за исключением периода Великой Отечественной войны. После возвращения с фронта орденоносец-артиллерист И. Г. Сулейманов, несмотря на подорванное войной здоровье и инвалидность, продолжил занятия наукой: сначала на стыке биологии и химии (кандидатская диссертация), затем биологии, химии и физики с применением новейших методов исследований (докторская диссертация). Позднее он стал заведующим кафедрой физиологии растений, признанным авторитетом по водному режиму растений[4]. Такой целеустремленности и работоспособности в сочетании с приветливым нравом можно только позавидовать[5].

В № 1 2005 г. журнала были опубликованы отрывки из воспоминаний И. Г. Сулейманова[6], а в настоящем выпуске вниманию читателей предлагается очерк-воспоминание об одном событии периода Гражданской войны, явившимся первым испытанием на мужество и оставившем глубокий след в памяти пятнадцатилетнего парня.

ПРИМЕЧАНИЯ:

1. Маһиярова З. Якташыбыз — олуг галим // Татар иле. – 2004. – № 44. – Октябрь.
2. Елисеева Н. С., Сулейманов Н. И. Сулейманов Исмагил Гадиевич // Фронтовики — ученые Казанского университета. – Казань, 2000. – С. 163-171; Сөләйманов Н. Ул үзе бер дөнья // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2005. – № 1. – С. 187-196; Архив КГУ, оп. ОК 15, св. 10, д. 230, л. 2.
3. Сөләйманов И. «Яшь чагымда аулда» (шигырь). Авторның шәхси архивыннан.
4. Татарский энциклопедический словарь. – Казань, 1999. – С. 547; Казанский университет (1804-2004): Библиографический словарь. – Казань, 2004. – Т. 3. – С. 354-355.
5. Елисеева Н. С., Сулейманов Н. И. Указ. соч. – С. 163-171; Архив КГУ, оп. ОК 15, св. 10, д. 230, л. 6, 9, 11; Боевая характеристика 1945 г. Из семейного архива автора.
6. Сөләйманов Н. Ул үзе бер дөнья... – С. 187-196.

Фото на с. 152: И. Г. Сулейманов в дни Ленинградской блокады на курсах по подготовке командиров батареи артиллерии. Лето 1943 г. Фото из архива автора.

Наиль Сулейманов,
научный сотрудник КГУ

Көрәш юлында. Беренче сынау һәм сыналу

Ул чорларда җәйнең матур көннәре иде. Июль кояшы үзенең нурларын чәчеп, булган җирне яктыртып һәм җылытып тора иде. Ул елны (1919) яңгырлар да вакытында булып, игеннәр үсәргә һәм җитешергә шартлар яхшы булды, арыш, тары, солы һәм башка игеннәр күпереп уңды. Арыш арасына зур кеше керсә күмелә торган иде, тик башакларны җилбер-җилбер килүен күреп кенә анда кеше булганын белергә мөмкин була иде.

Барлы-юклы болында да үлән зур һәм матур булып үсте, аллы-гөлле чәчәк атып, дөньяны матурлап тора иде. Үлән эченә күмелеп, дөнья кайгыларын таратып һәм онытып, рәхәтләнеп йөрисе, ауныйсы килә иде. Яшел хәтфә кебек болын, ничектер, үзенә тарта кебек, кил син, балам, «кил син, анам һәм кызларым, кил кочагыма кер, ямьле җәйнең рәхәтен күр», – дигәндәй булып күпереп тора иде. Сәвәде суы да ул көннәрдә киң булып, шыбыр-шыбыр итеп ага иде. Каз һәм үрдәк бәпкәләре су эчендә чумыш-чумыш уйныйлар, бер чумалар да бер чыгалар, башын күтәреп карыйлар да, тагын суга кереп югалалар иде.

Кая барсаң да, кая карасаң да табигатьнең матурлыгы сокланырлык, карап туймаслык, хуш исләре башка китәрлек, җанга җитәрлек, кайгы йомгагын сүтәрлек кебек иде. Агач башындагы каргалар да бер очалар, бер куналар. Алар да матурлыкны аңлыйлар кебек, үзләренчә хыял диңгезендә йөзәләр кебек иде.

Малларга да матур шартлар туган, ашап-эчеп, болын кичеп, иясенә хезмәт итеп, сука сөреп, сөт биреп, рәхәтләп торырлык, кеше күңелен күрерлек, ямьле табигатьнең матурлыгын арттырып, моңлы уйны таратып, «яшәргә кирәк, яшәргә» дип әйтә белмәсәләр дә, аларга карап шулай уйларга мөмкин иде. Табигатьне матурлыгын күреп һәркем үзенчә хис итә, һәркем үзенчә файдалана, күңел ача һәм юата, зур кайгыларын югалта.

Ләкин ул матурлыкларның берсе дә күзгә күренерлек, аңа карап күңел юатырлык, кайгыларны таратырлык булмады. Басу эшләрен дә вакытында эшләргә, кирәгенчә ки-

черергә туры килмәде. Малларны да абзардан чыгармаска туры килде, аларны чабып алып кайткан печән белән генә тамакларын ялгадык, туйганчы ашатырга мөмкин түгел, чөнки күкрәп үскән иген басуында, болында аклар гаскәре тора иде. Басуда һәм болында эшләргә дә рөхсәт итмәделәр. Чөнки ул чорларда гражданнар сугышы бара иде. Безнең авылны бер кызыллар, бер аклар килеп алалар иде, озак тормый китәләр иде. Килер алдыннан һәм авылдан китәр алдыннан да мылтык һәм туп аткан тавышлары ишетелә иде Сәвәдәнең аргы ягында һәм әрәмәлек буенда.

Безнең гаиләдә җиде кеше иде: авыру анам, апам, сеңлем, ике агам, туганым Гали һәм мин. Зур агам күрше авылда икмәк хәзерләү пунктында эшли, хезмәт итә иде, кызыллар оештырган урында. Икенче агам өйдә йорт эшләрен карап, гаилә эшләрен алып бара иде. Күрше авылларда һәм бездән ерак авылларында да туган тиешле кешеләр яши иде.

Бездән кырык чакрым ераклыкта, Аташ авылында әтинең бертуган апасы тора иде. Аның уртанчы малае Солтанәхмәт патша хезмәтеннән баш тартып, сугыш елларында (1914) урманда качып йөрде. Ул анда кызыл партизаннар белән танышкан, алар группасына кушылган, алар белән бергә хезмәт иткән, гражданнар сугышы башлангач, аклар торган авылларга, шәһәрләргә барып гаскәрләр өчен кирәк булган төрле мәгълүматлар җыеп, кызыллар штабына җиткерә торган булган. Партизан отрядының боерыгын үтәгән вакытта, бер көнне тотып алалар, нык кына кыйнап, аның нинди, кайдагы партизан отрядыннан икәнен әйттерергә тырышканнар, бернинди дә кирәкле мәгълүмат бирмәгәч, Уфа шәһәренең төрмәсенә япканнар (утыртканнар). Күпме вакыт анда яткандыр, белмим, ләкин шуны хәтерлим, Уфага кызыллар якыная башлагач, төрмәдәге кызыл партизаннарны, күз алды караңгылангач, аклар алып чыкканнар һәм көнбатыш якка алып киткәннәр җәяүләп. Аларны сафка тезеп барганнар, дүрт яктан да мылтыклы солдатлар чолгап алган булган. Бер авылның читеннән ындыр буйлап барганда сафта тавыш күтәрелгән, берничә ристан качарга дип сафтан чыгып йөгергәннәр, алар артында мылтыклы солдатлар мылтык ата-ата кычкыра һәм куа башлаганнар, шул тәртипсезлектән файдаланып, Солтанәхмәт абзыкай Иван белән кычыткан эченә кереп яткаННар (егылганнар). Кычыткан арасына керүнең үзләренчә сәбәбен алдан хәзерләгәннәр. Ләкин аларның сафтан чыгып китүләрен, кычыткан сикереп керүләрен күрми калганнар, ахры (Солтанәхмәт абзыкай әйтүе буенча), аны белгәч, башта дүрт аяклап, аннан соң аякка басып, тавыш чыгармый, бер бакчадан чыгып, икенче бакчага кереп йөгерә башлаганнар. Ул авылның артында куе урман бар, шунда барып чыкканнар. Урманны үтеп чыгып, иген басуына барып кергәннәр. Ул арада таң ата башлаган. Хәлдән таеп, иген басуына кереп яшеренгәннәр, утырып ял иткәннәр. Солтанәхмәт абзыкай безгә килергә дип юл тоткан. Көндезен басуда иген арасында качып торып, төннәрен, көн караңгылангач, юлсыз басулар аркылы алга барганнар. Ике көн үткәч качуларына, Солтанәхмәт абзыкай ристаннар киемендә, зур сакаллы, кичен көн караңгылата башлагач, ындыр аркылы безгә килеп керде. Танырлык та түгел иде. Ачыккан, хәлдән тайган, беренче соравы шул булды: «Бәширдә кемнәр тора, аклармы, кызыллармы?» Кызыллар, дигәч, тыныч ланып китте. Аның партизан булганын әлегә кадәр ишетеп кенә белә идек, ул чын булып чыкты, хәзер үзебез күрдек. Анам ашатты, эчертте, аның тамагын туйдырды, шуннан соң ристан киемнәрен салдырып, Хөсәен абзыкайның иске киемнәрен кидердек, яңа киемнәр юк иде. Хөсәен абзыкай аның сакалын элек кайчы белән кыркып алды, аннан пәке белән кырды. Адәмгә ошап китте. Чәчләрен дә алды. Нигә бу хәлдә булганын һәм килгәнен безгә ишеттерми, зурларга гына сөйләде. Алар сөйләшкәндә әгәр якын барсаң, сүздән туктыйлар иде. Аның нигә бу хәлдә килгәнен без — балалар тик берничә көннән соң гына белдек.

Солтанәхмәт бездә бер-ике көн торып, Баскак авылына китәм дип тора иде. Бу авылда, аның белүе буенча, кызылларның штабы булырга тиеш. Анда барып күренеп, партизан отрядын табарга, яңадан эшкә тотынырга дип торган. Ләкин хәлләр бик тиз үзгәреп китте, кызыллар чигенә башладылар, Хөсәен абзыкай, староста боерыгы буенча, алар белән бергә олау белән китте.

Көтмәгәндә безгә аклар килде. Зур атышулар булмады, тик берничә урында мылтык аткан тавышлар берничә сәгать буенча ишетелеп торды (килеп-килеп ишетелә иде). Аклар килү мөнәсәбәте белән анамның һәм Солтанәхмәт абзыкайның авыр хәлдә калганнары, кәефләре бозылганы йөзләреннән күренеп тора иде. Анам карчык мине чакырып алды, нигәдер юрган белән каплады, үзе дә шуның астына керде. Салиха апага әйтте, әгәр дә йорт ишегалдында торган аклар солдаты өйгә керә башласа, безгә әйтергә дип. Юрганга капланган килеш, кеше ишетмәсен дигән кебек, минем колагыма Солтанәхмәт абзыкай турында сөйләде. Солтанәхмәт абзыкайның үз исеме белән әйтмәскә кушты, нинди исем белән эндәшергә кирәген хәтерләмим. Безнең ялчыбыз дип йөртәбез, диде. Аның белән грубый итеп сөйләшергә, туганнарча булмаска кушты. Шулай итеп без Солтанәхмәт абзыкай белән ялчы белән бай арасындагы мөгамәләгә күчтек. Ялчыны сарайда арбада төн кундырырга булдык. Анда йоклау бездә гадәт буенча иде, үзебез дә еш кына арбада йоклый идек тыныч вакытта, саф һавада. Ул акларга ошамады, өйгә керергә куштылар.

Без беребез дә русча белми идек. Солтанәхмәт абзыкай да белмәскә салышты, чөнки хуҗа белми торып, ул белгәнен күрсәтсә, шикләнә башлаулары бар иде. Эшләгән булып ул солдатлар янына бара иде, анда эш табып кыймылдый башлый. Бигрәк тә, солдат янына командир килсә, колагын салырга, аларның сүзләрен ишетергә тырыша иде. Солдатларның беразы йорт ишегалдында, калганнары тауга менеп, ашарга гына кайта иде. Алар урынына өйдәге солдатлар бара иде.

Бердәнбер көнне ул нәрсәдер ишеткән, секретный нәрсә булгандыр, ахры. «Штабка җиткерергә кирәк булган бик мөһим хәбәр бар, мин Баскак авылына китәм, – ди. Тик менә нинди юл белән аклар фронты аркылы, аларга тотылмыйча китәргә?» Ул авылга китү өчен Солтанәхмәт абзыкай ике вариант уйлаган. Бер варианты буенча авылның аргы очына барып, тау итәгендә һәм башында үсә торган иген басуы, арышлар аркылы китәргә, әгәр анда гаскәр булмаса. Ләкин бездән бер чакрым ераклыкта Яңа Бәшир авылы бар, анда аклар бармы-юкмы, белмибез. Әгәр анда аклар булса, акларның постларына эләгүе бар. Әгәр эләксәң, аңарга да, безнең гаиләгә дә аклар тарафыннан яхшылык көтәргә ярамый, чыгарып атулары бар. Андый хәлләр булуын ишеткән идек. Яңа Бәширгә йомыш белән барып белергә дип план төзедек. Ләкин ул планны үткәреп булмады. Югары очка барып халыктан сораштык. Алар әйттеләр: «Иске Бәшир белән Яңа Бәшир арасында акларның постлары тора, беркемне дә үткәрмиләр», – дип. Ул юл белән барырга мөмкин булмагач, Солтанәхмәт абзыкай икенче вариант тәкъдим итте. Аның нидән торганын язганчы, башлар акларның фронты кайдан үткәне турында сөйлим, таныштырыйм әле.

Безнең авылның бер ягы тау башында, икенчесе түбәндә, сусыл урында салынган. Тауга безнең турыдан менсәң, ике зират күрәсең, аларның арасы йөз метр чамасы. Сул як зиратта безнең күршеләрдә һәм бездә торган солдатлар постка менә торган булган, ә уң зиратта икенче урамнан тыкрыктан күтәрелә торган булганнар. Аны Солтанәхмәт абзыкай алдан күзәтеп торган булган.

Бездә рус солдатлары торды, безнең күрше Кәли абзыкайларда Шәрифулла исемле бер татар солдаты бар иде. Ул безнең коега атлар эчертергә килә иде. Шул вакытта безнең ялчы аның белән сөйләшкәләгән, танышкан. Шәрифулланы мобилизация юлы белән алганнар, сугыш беткәнен ул ике күзләп кәтә иде, чөнки гаиләсе бар, аны сагынган, балаларын күрәсе килә. Сугыш булгач сугыш инде, чит илдә башыңны калдыруың бар, яки нык җәрәхәтләнеп китүең бар. Хәзер Солтанәхмәт абзыкайның икенче вариант белән кызылларга китүе турында язам.

Бу вариант буенча Солтанәхмәт абзыкай белән миңа ике зират арасыннан көпә-көндез аклар торган фронты аркылы нейтраль урынга чыгарга, аннан соң болын, аның артында арыш басуы башлана. Зиратлардан арыш басуына кадәр 500-600 метр булгандыр. Болынга кергәч, зиратлар югала башлый, күренми. Уң зиратларны үткәч тә сабан ашлыгы башлана. План буенча арыш басуына таба барырга тиеш идек, чөнки анда яшеренергә мөмкин иде, сабан ашлыгы басуында качарга уңайсыз, анда игеннәр биек булып үсми бит. Солтанәхмәт абзый солдатлардан ишетеп калган, олау кирәк икән, нигә икәнен белми, алга барыргамы яки чигенергә кирәкме. Аның планы буенча без йөгәннәр тотып туп-турыга ике зират аркылы атлар эзләргә дип барырга тиешбез (көпә-көндез). Әгәр аклар фронтын үтәлсәк, арыш басуына барып җиткәч ул анда кала, көнне шунда яшеренеп үткәрә, кичен, күз алды караңгыланган, Баскак авылына юл тотачак. Аның өчен кызыллар фронтын үтәргә кирәк була. Аклар ягыннан килгәннәрне кызылларның атуы бар. «Анысын ничек булса да үзем хәл итәрмен», – диде. Бу планны анам мәрхүм яраклы дип тапты, безнең исән-сау кичүне теләп, елап калды. Ләкин елаганны акларга белдерергә ярамый дип Солтанәхмәт абзыкай аны тынычландырырга тырышты.

Көн бик матур кояшлы иде, без икәү иртәнге чәйне эчтек тә йөгәннәр тотып тау башына таба киттек. Зиратларның уртасы турына барып җиткәч, сул як зираттан мылтык күтәреп кычкыра башладылар. Аңа кадәр дә кычкырганнар иде, аны ишетмәгәнгә салынып без бара бирдек. Ике як зираттан да бик кычкыргач, туктадык. Шуннан соң мылтыгын безгә төзәп ике солдат килделәр. Солтанәхмәт абзыкай миңа әйтә «курыкма» ди, «атмыйлар» ди. Солдатлар килеп нәрсәдер сорый, сөйли башладылар русча, кулы белән кире кайтырга күрсәтә башладылар. Без бер-беребезгә карап торабыз болар нәрсә сөйлиләр икән дип. Солтанәхмәт абзыкай аңламаганга салышты. Без йөгәнне башка кидереп болын ягына барырга дип күрсәттек. Ул вакытта миңа барлыгы ундүрт яшь иде, үзем куркам да, ләкин курыкканны белдермәскә тырышам. Шуннан бер солдатны, командирыдыр, ахры, чакырып алды, икенчесе мылтыгын безгә төзәп басып калды. Зираттан безнең янга безнең күршедә тора торган Шәрифулланы җибәрделәр, татарча белгән солдатны. Аңарга «без атлар алырга барабыз», – дидек. «Алар нигә кирәк?» – дип сорамады, аңарга безнең җавап хәзерләнгән иде. Безнең сүзләрне Шәрифулла командирга барып әйтте дә борылып яңадан килде. «Сезнең атларыгыз кайда?» – дип сорады. «Кайдалыгын төгәл белмибез, моннан дүрт-биш көн элек болында калдырган идек», – дип, аның кайда икәнен күрсәттек. «Бәлки шундалардыр, яисә берәр якка киткәндер, дидек. Игеннәргә генә кермәгән булса ярар иде», – дип куйдык. Шәрифулла безнең җавапны командирга барып сөйләде. Бераздан соң аның рөхсәт иткәнен безгә

килеп әйтте. Моны искә алу җиңел түгел бит, күзем тула яшь белән, чөнки нервылар тимер түгел бит.

Кайткан вакытта сул як зиратның көнбатыш ягыннан кайтырга куштылар, атны җитәкләп кайтырга, атланмаска, әкрен генә кайтырга, гел зиратка карарга, «югыйсә атып үтерербез», – дип янап куйдылар. Шул шартлар белән боерыкны алгач, без алга таба киттек.

Солтанәхмәт абзыкай бераз шикләнгән булган, әзрәк киткәч, безне арттан атып үтерүләре бар дип. Ул турыда миңа соңыннан әйтте. Бара торгач, без болынга кереп күз каршыннан югалдык, тизрәк атлап арыш басуына барып кердек. Утырып хәл җыйдык, әзрәк тыныч ландык. Шуны әйтергә кирәк, ул болында безнең атлар юк иде, бәлки берәр ат очрар әле дип тәвәккәлләп киттек. Әгәр дә бер ат та очрамаса, икебез дә Баскаклыга китәргә булдык. Ләкин икебезнең дә күз каршыннан югалу куркынычлы иде, аны аклар белеп, гаиләне җәзалаулары бар иде. Эзләнә торгач, арыш арасында порх-порх иткән тавыш ишетелде. Әйләнгәләп карасак, арыш арасында, уедык урында бер ат ятып торганын күрдек. Читтән карап күренерлек түгел. Кечкенә казыкка сүс җеп белән каты итеп бәйләп куйганнар, аягын тышаулаганнар. Безне күргәч, ат шатланып киткән кебек булды. Кем аты икәнен мин бер күрүдә үк белдем. Безнең авылның Муллаҗан абзыйның аты иде. Ул бик данлыклы ат. Сабан туйларында чабышып беренче урынны ала иде, призлар бирәләр иде хуҗасына. Бәлки арыш арасында тагын атлар бардыр дип эзләргә башладык. Дөресе, мин ат янында басып калдым, Солтанәхмәт абзыкай эзләргә китте. Бераздан соң әйләнеп кайтты, бер ат та тапмаган. Муллаҗан абзыйның атын алып кайтсак, аны аклар алып китүе бар, болай да авыл буенда яхшы атлар эзлиләр дип ишеткән идек. Атсыз кайтырга да ярамый. Нәрсә эшләргә? Иске хәсрәт өстенә яңа хәсрәт өстәлде. Мәсьәләне «ничек хәл итәргә инде?» – дип бер утырып, бер йөреп уйладык. Башка килде шундый уй. Сул як зиратның көнбатыш ягында Габдеррәфикъ бабайның ындыры бар, аның артында тирән Карагай чокыры бар, шул чокырга төшереп тышаулап, туры килсә бәйләп куярга булдым. Башта Солтанәхмәт абзыкай китте, аны озатып, исәнләшеп-саубуллашып, сугыш беткәч тыныч вакытта күрешергә булсын дип, теләкләр теләп аерылыштык. Аерылу җиңел булмады, ләкин нигәдер күзгә яшь тулмады. Бер үзем генә калгач утырып корган планнарны тагын уйлап карадым. Торып ат янына бардым, башына йөгән киердем һәм тышавын алдым, карыйм, ат көчкә атлый, чөнки ничә көннәрдер, ахры, ат тышаулаган көйгә торгач, аяклары уелган булган. Тезгеннән тотып кайту ягына әкрен генә юл тоттым. Ике нәрсәдән куркыныч калды: берсе шуңардан: аклар без киткәнне онытып, атып үтерүләре бар, икенчесе — сез икәү идегез, кайда калды, ник кайтмады, кызылларга качтымы, дип гаепләүләре бар. Шуңардан курыктым.

Арыш басуыннан болынга килеп чыктым. Үлән матур, аппак чәчәкләр үсеп торалар, ләкин башта үлем куркынычы булды, ул матурлык бернинди тәэсир итмәде. Бара торгач зиратлар күренә башлады. Сул яклап ярты җир буе урында нәрсәдер сызгырган дай бик тиз булып килә дә тавыш, югала. Бара торгач, миннән ерак түгел урынга килеп выж-выж итеп төшә башладылар. Зират ягында нәрсәдер шытыр-шытыр килә (ул вакытта мин пулемет атканын ишеткәнем юк иде әле). Биш-ун метр чамасында минем янга якынлашып чыжлап төшә башладылар. Мин туктадым да зират ягына төсмерләп карый башладым. Әллә кул болгадымы, белмим, тик шуны хәтерлим, зираттан картуз белән, нәрсә беләндер, миңа сигнал бирделәр миңа уңга китәргә кушалар дип аңладым, чөнки шул якка таба күрсәттеләр. Мин нык борылып сул якка бара башладым. Зиратның сул ягына чыгып кайдан төшәргә кирәкне кул болгап күрсәттеләр, атуны туктаттылар. Бу бәладән котылдым дигәндә икенче бәла килеп чыкты. Габдеррәфикъ ындыры янында да, чокыр кырыенда да часовой торганын күрдем. Ничек итеп чокырга төшәргә? Атны хуҗасына илтеп бирсәң ярамый, ә чокырга илтергә куркынычлы. Шулай икеләнеп торганда Габдеррәфикъ бабайларның артыннан Мортаза абзый ат җитәкләп килеп чыкты, шуны күргәч, минем эчкә җылы керде. Ике ындыр арасыннан атны җитәкләп, зиратларга карый-карый әкрен генә киттем. Беренче часовойны үттем, бер сүз дә әйтмәде, икенче часовой, чокыр читендә торганы нәрсәдер әйтте, мин кул белән чокырга күрсәттем, тышауларны болгап куйдым. Берни дә әйтмәгәч, чокыр төбенә төшеп киттем, атны нык итеп тышауладым. Часовой минем арттан карап торды. Кайдан кайтырга? Килгән эздәнме я югары оч урамыннан. Шулай уйлый-уйлый бара торгач, Нәби абзыйларның бәрәңге бакчасына барып чыкканмын. Ул арада бик нык кычкырган тавыш ишеттем, әлек белмәдем нигә кычкырганнарын. Читән артында мылтыгын миңа төзәп часовойны күргәч, миңа кычкырганын аңладым. Аңардан ерак түгел Нәби абзыйның зур малае Сафый абзыйны күрдем, басып тора иде. Часовой янына тагын бер солдат килеп чыкты, икәүләп кычкыра башлагач, Сафый абзый аларга кулы белән күкрәген күрсәтеп нәрсәдер әйткәч, кычкырудан туктадылар. Шуннан соң миңа Нәби абзыйлар йортына кул белән күрсәттеләр. Минем бу рөхсәт итү дип Нәби абзыйлар йортына юнәлдем. Сафый абзый янына барып мин аңарга атлар эзләп йөрдем дип әйттем. Ләкин эч серен сөйләмәдем. Кардәш кеше булса да, анам берсенә дә әйтергә ярамый дигәч, серне чишмәскә бул-

дым. Алар гына түгел, бу вакыйганы беркем дә белмәгәндер, чөнки ул вакытта аның хакында сөйләргә ярамый иде. Нәби абзыйларда утырып, әзрәк торгач үзебезгә кайтып киттем.

Анам бик куркып торган, мине зур шатлык белән җылый-җылый каршы алды. Аны аклар күрмәде. Бик ачыккан идем, ашадым, эчтем, аннан соң нәрсә эшләгәнемне хәтерләмим. Тик шул истә калган, кичкә таба солдатлар бричкаларын карап йөрделәр, дегетләделәр дә, ахры. Безнең ялчыны сорарлар дип куркып тордык. Аларның үз кайгылары көчлерәк булды, ахры, аны искә алмадылар.

Кич булды, күз алды караңгыланды, солдатлар бүтән көннәргә караганда үзара сөйләшеп шәп-шәп итеп йөрделәр. Анам әйтә: «әллә китәргә хәзерләнәләр, бик яхшы булыр иде», – дип куйды.

Төнне торып иртәгә таба нәрсәдер үзара сөйләшәләр, чыш-пыш итеп, нәрсәгәдер хәзерләнәләр. Чыннан да бераздан соң капканы ачып, атларын чаптырып чыгып та киттеләр, шуңа кадәр командирлары нәрсәдер кычкырынган иде.

Иртән карасак, аклар телефон чыбыкларын да алып өлгермәгәннәр, сузылган көйгә калдырып киткәннәр. Без яшь балалар аны кискәләп, өзекләрен үзебезгә ташый башладык.

Ул арада Калмаш ягыннан авылга кызыллар килеп керделәр. Телефон чыбыгына тотынмаска куштылар. Кичә кичен авыл артында атышлар ишетелгән иде, безнең урамнарда мылтык атучылар булмады.

Безнең авылга бер аклар, бер кызыллар килеп еллар буена алмашынып йөрсәләр дә, үткән вакыйга бер генә булды. Бүтән вакытта аларны ашатып, эчертеп, мунча кертеп, хәстәрен күрүләр генә истә калган. Тавыкларны тотып, берәм-берәм пешертеп ашаганнарын хәтерлим, анам карчык бик елаган иде ахры, тавыкны суйдырып пешереп ашагач, нәселгә дә тавыгыбыз калмады дип.

Кызыллар күрше Ихсан авылыннан да, Усман абзыкай икмәк хәзерләү эшендә эшли торган авылдан да акларны куып җибәрделәр.

Шул көнне кичен ул өйгә кайтты. Кызыллар өчен икмәк җыйганны белеп, аклар безне җәзаларлар дип бик курыккан. Без исән-сау булгач, шатланып китте. Солтанәхмәт абзыкайның килгәнен, фронт аркылы аны озатканны ул бөтенләй белмәгән. Ул хакта сөйләгәч, бик куркынычлы вакыйга булган икән, минем белән дә киңәш итәргә кирәк иде дип куйды. Аның сугыш тәҗрибәсе бар иде. Беренче империалистлар сугышында ул Румын фронтында булган иде.

Ике көннән Хөсәен абзыкай кайтты (олау белән киткән агам). Ул безнең авылдан утыз чакрым китеп, бер рус авылында кызыллар солдаты белән бер атна торган. Аклар чигенә башлагач, аларны (олаучыларны) кайтарып җибәргәннәр.

Әхмәтсолтан абзыкайны ничек озатуны сөйләгәч, «андый эшне бик сак эшләргә кирәк, үз башыңа үзең җитүең бар, – ди. – Ярый әле очрак рәвештә барысы да уңай үткән. Әгәр берничә көн торсалар, сездән ялчыны таптырулары бар иде. Гаепләп тә куярлар, газапсыз да калдырмаслар иде. Бәхетегезгә андый хәлләр булмаган».

Атна буена бик зур напряжение белән торгач, аклар киткәч, рәхәт булып китте, иркенләп тын ала башладык. Тик яңадан шул ук гаскәр килсә, үткән вакыйгаларны тикшерүе бар иде. Ярый әле яңадан тиз килмәделәр, килсәләр дә тиз китә бирделәр, таныш булмаган гаскәрләр.

Бу вакыйгадан соң Солтанәхмәт абзыкайны бер мәртәбә күрдем. Ул миннән аерылып киткәч, басу уртасыннан барган, ерактан кеше башлары күренгәч, кичкә кадәр бик саклык белән кайда бөгелеп, кайда дүрт аяклап барган. Кызыллар фронтын кичен күз алды караңгылата башлагач үткән. Басуда тагын атлар очраган, аларны атланып китмәгән, җәяү барган. Ул ике авыл арасында елганы үткән. Якын тирәдә часовой очрамаган. Шул көнне Баскак авылына барып җиткән һәм кызыллар командирына үзенең башыннан кичкән вакыйганы сөйләгән, аклар Калмаш авылына (анда кызылларның фронты үтә иде) төньяклап һөҗүм итәргә план төзегәннәрен ишеткән, шуның хакында әйткән. Шуннан соң аны яңадан партизан отрядына җибәргәннәр. Сугыш беткәнче анда хезмәт иткән, төрле заданиеләр үтәгән, акларга тагын эләгеп, тагын котылган. Сугыш беткәч, дөньялар иминләнгәч, берничә ел буена аның хәбәре булмады. Мин укырга киттем, ул да укыган күрәсең. Тик берничә ел үткәч аның Башкортстанда, Мәүлүт районында урта мәктәпнең директоры булып эшли дип ишеттем. Шул мәктәптә эшләгән хәлфәдән ишетеп белдем.

Яшь чагында тәвәккәл буласың, күрәсең, күп уйлап тормый эшлисең, карт көндә андый эшләргә риза булу өчен күп уйланган булыр идең әле. Ул вакытларда сугышның ни икәнен күреп белмәгәч, гади нәрсә дип каралган, шулай итеп башлангыч хәрби белем алдым, теоретик яктан түгел, практик яктан, кечкенә булса да, үз башыңнан кичергәч, ул хәл гомер буена онытылмады, хәтердә сакланды. Шуның белән бергә акларга карата дошманлык уе, аларның кешесезлекләрен үз күзем белән күрдем. Ул яктан чыгып та бу вакыйга дөньяны танырга өйрәтте, кешеләрне аңларга юл күрсәтте.

Исмәгыйль Сөләйманов.